РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

19 май 2026 ел Буа шәһәре № 4-12

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 4-54 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу әһәмиятсез булса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 4-54 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу әһәмиятсез булса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3, 4, 5 пунктларның 2 абзацында һәм 6, 11 пунктларның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентының гаризасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе гаризасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы
вазифасын башкаручы И.Ф. Еремеев